**ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ**

Татарстан Республикасы
Ютазы муниципаль районы
Ютазы авыл җирлеге Малиновка торак пунктында халык җыены нәтиҗәләре турында

**«15» декабрь 2021ел** **№4**

2003 елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы 131-ФЗ санлы Федераль законның 25.1, 56 маддәләре, 2004 елның 28 июлендәге «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»гы 45-ТРЗ санлы Татарстан Республикасы Законының 35 маддәсе нигезендә, 2021 елның 15 декабрендә узган гражданнар җыены беркетмәсе төзелде: «2022 елда Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Ютазы авыл җирлегенең Малиновка торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 400 (дүрт йөз) сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм аны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә җибәрүгә сез ризамы:

- Малиновка торак пунктындагы юл-урам челтәре торышын норматив хәлгә китерү (юл төзү, төзелеш материаллары сатып алу, алып кайту, вак ком-таш катнашмасы җәю, проект-смета документлары әзерләү, эшләр өчен килешү буенча түләү);
- Чишмәне ремонтлау һәм реконструкцияләү (материаллар сатып алу, проект-смета документлары әзерләү, эшләр өчен килешү нигезендә түләү).

Халык җыены нәтиҗәләре турында беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә 26 кеше кертелгән, тавыш бирүдә 16 кеше катнашты.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:
җыенда катнашкан 16 кеше «РИЗА» позициясе өчен тавыш бирде; «КАРШЫ» позициясе өчен җыенда катнашкан 0 кеше тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә, халык җыены түбәндәге карар кабул итте:

1. Ютазы муниципаль районы Ютазы авыл җирлегенең Малиновка торак пунктында халык җыены узган, нәтиҗәләре дөрес дип санарга.
2. "Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Ютазы авыл җирлеге Малиновка торак пункты территориясендә һәр балигъ булган кешедән, I һәм II төркем инвалидларыннан, Бөек Ватан сугышы ветераннарыннан, Россия Армиясе сафларында хезмәт итүчеләрдән тыш, 2022 елда үзара салым кертүгә 400 сум күләмендә акча кертү белән килешәсезме?:

1) Малиновка торак пунктындагы юл-урам челтәре торышын норматив хәлгә китерү (юл төзү, төзелеш материаллары сатып алу, алып кайту, вак ком-таш катнашмасы җәю, проект-смета документлары әзерләү, эшләр өчен килешү буенча түләү);

2) Чишмәне ремонтлау һәм реконструкцияләү (материаллар сатып алу,

проект-смета документлары әзерләү, эшләр өчен килешү нигезендә түләү)- карарын кабул ителгән дип санарга.

3. Җыелышның нәтиҗәләрен Ютазы авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә һәм Ютазы муниципаль районының рәсми сайтында түбәндәге адрес буенча: http://jutaza.tatarstan.ru, хокукый мәгълүматның рәсми сайтында түбәндәге адрес буенча: http://pravo.tatarstan.ru кабул ителгән көннән 5 көн эчендә бастырырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Ютазы авыл җирлеге башлыгына җибәрергә.

Халык җыенында рәислек итүче,
Ютазы муниципаль районы
Ютазы авыл җирлеге башлыгы

Р.М.Галимов